Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Нижнебишевского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Ул. Центральная, д. 46, с. Нижнее Бишево,
Заинский район, 423514

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
башкарма комитеты

Центральная урамы, 46 нче йорт,
Түбән Биш авылы, Зәй районы,
423514

Телефон, факс 68-4-47. Электронный адрес: Nbsh.Zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/nizhnebishevskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 16** **30.07.2019 ел**

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.
4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Түбән Биш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Д.В.Насертдинов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Түбән Биш авыл җирлеге
Башкарма комитет карарына
Кушымта
30.07.2019ел № 16

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге**

| № п/п | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1478 | Мәгълүмат стенды<br>Түбән Биш авылы, `Үзәк ур., 16 йорт |
| 2. | 1479 | Мәгълүмат стенды<br>Куш Елга авылы, `Үзәк ур., 53 йорт |
| 3. | 1480 | Мәгълүмат стенды<br>Пуст-Ашит авылы, Г.Тукай ур., 9 |
| 4. | 1481 | Мәгълүмат стенды<br>Шыкмай авылы, Үзәк ур., 27 йорт |